ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» 02 2026 ел №95

2026 елга "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 № 8-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 23.01.2026 № 30 карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 25.06.2025 № 29 карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл һәм шәһәр җирлеге Башкарма комитетларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы 28.11.2025 елгы килешүләр нигезендә, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең Татарстан Республикасы Ютазы районындагы клиент хезмәтенең (бүлек хокукларында) 26.01.2026 ел, № 25-32-52/7918 «01.02.2026 елдан СФР тарафыннан башкарыла торган түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү турында» хатына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2026 елга «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарга 1 һәм 2 нче кушымталар нигезендә 9678 сум 63 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
тел. 2-42-05

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
04.02.2026 №95

2026 елга «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге (табутка күмү) нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3869,11 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1182,61 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 4626,91 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта
04.02.2026 №95

2026 елга «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе (тән киеме белән җирләү)

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Тәннең киеме | 898,00 |
| 3. Күмү өчен кирәкле әйберләрне китерү | 2971,27 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1182,64 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 4626,72 |
| Барлыгы | 9678,63 |